Ислам нуры
اسلام نورى
«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)
12+
№ 7 (683) 12 апрель 2019 ел (1440, Шәгъбан) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

# Изге ниятtә булыгыз



Киемнәрегезне, тәннәрегезне кер вә пычраклардан пакьләгән кебек, күңелегезне дә икейөзлелек, алдау, үч тоту, көнчелек, ачу, золым кебек бозык холыклардан пакь итегез! Аллаһы Тәгаләгә шөкер иту вә Аллаһының Тәгаләнең ихласлы бәндәләре белән бер җиргә җыелып, мәхәббәт вә бердәмлек барлыкка китерү нияте белән намазларны мөмкин кадәр җәмәгать белән үтәгез! Ураза тоткан вакытыгызда, нәфесне тәрбияләү, сабыр итүгә гадәтләндерү, фәкыйрь вә мескеннәр хәлен сынап карауны ният итегез! Малыгыздан зәкят биргән вакытыгызда, юмартлыкка гадәтләнү, саранлык кебек бозык холыктан нәфесне сафландыру, фәкыйрьләрне шатландыру кебек изге ниятtә булыгыз! Ислам кардәшләре белән танышу, мәшәкатьләргә гадәтләнү, сәяхәт итеп гыйбрәтләнү нияте белән — фарыз булган хаҗ сәфәренә барыгыз!

*(Риза Фәхреддин, "Әхлак гыйлеме".)*

# Төзелеш гөрли




"Чаллы Яр" мәчете төзелешенә узган елның май аенда нигез салынган иде, бүген анда кызу эш бара. Шәһәрнең имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, төзелеш бары-шы белән янә танышып кайткач: "Юл кырыенда мәчет төзү нияте күптән бар иде. Чөнки Казан юлында андый мәчетләр күп, алар сәяхәтчеләр, юлчылар өчен намаз укырга, тукланып алырга бик уңайлы. Диния нәзарәтеннән безгә дә мондый мәчет салырга тәкъдим булган иде, төзелеш өчен җирне юл кырыеннан биргәч, сөенеп куйдык. Бу урында шәхси йортлардан торган яңа комплекс та булачак икән. Шушы мәчет беренче чиратта халыкка хезмәт күрсәтәчәк, ә аннары инде юл мәчете функциясен үтәячәк дип әйтергә була. Үзебезнең теләккә ирештек һәм, Аллаһ боерса, җәй көне мәчетебезне ачып җибәрербез дип уйлыйм", - дип, үз фикерләрен җиткерде.

"Аллаһы Тәгалә миңа бу мәчетне вакытында һәм матур итеп төзергә вазыйфа бирде. Һәр кеше йөрәгендә иман белән туа, шуңа күрә булышырга теләүчеләр күп, мөхтәсибәт, Диния нәзарәте һәм шәһәр җитәкчелеге дә ярдәм итеп тора. Шәһәребез хәзерге заман стилендә булгач, мәчетне дә хай-тек стилендә төзергә булдык. Монда тәһарәт алу, намаз уку өчен бөтен уңайлыклар да булачак. Мәчет янында дини мәрасимнәр үткәрү залы һәм ашханә дә каралган. Мәчетнең биеклеге якынча 9 катлы йортка тиң, чөнки ул эрактан күренеп, шушы урында мөселманнар яшәгәнен билгеләп торырга тиеш. Безнең татар халкы, гомумән, мөселманнар, электән авыл яки шәһәр төзи башлаганда, беренче булып мәчет салганнар бит... Мәчет 250 кешегә исәпләнгән", - дип, мәчет төзелешенә бәйле фикерләрә белән Илдар хәзрәт Зияров та уртаклашты.

# Яшьләр көрәште

Мөселман яшьләренең Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте кубогына кул һәм татарча көрәш буенча берләштерелгән турниры елдан-ел популярлаша бара. 30 мартта Чаллының "Витязь" спорткомплексында мондый бәйге унберенче тапкыр, һәм, һәр елдагыча, Рәсәй күләмендә уздырылды. Ярышта Оренбург, Самара, Удмуртия, Башкортостаннан, Татарстанның Әлмәт, Әлки, Буа, Яңа Чишмә, Актаныш, Кукмара, Алабуга, Саба, Мөслим, Менделеевск, Азнакай, Мамадыш, Зәй, Минзәлә, Биектау, Балтач районнарыннан 116 спортчы көч сынашты. Алар барысы да намаз әһелләре иде һәм, турнир шартлары буенча, иң башта намаз кагыйдәләре буенча имтихан үттеләр.

Турнирны ачу тантанасы Коръән укып башланды, аннары дога кылынды. Катнашучыларны Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, шәһәр хакимияте башлыгы урынбасары Рамил Хәлимов, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Диния нәзарәте мөфтие урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов котлады һәм спортчыларга уңышлар теләделәр.

Үз авырлык төркемнәрендә беренче урынны яулаучылар арасында олуг хаҗга юлламa оту буенча шобага салу булды. Биредә бәхет Чаллының яшь көрәшчесе Данил Дамир улы Хәйриевка елмайды. Турнирның иң дәрәҗәле бүләген аңа Җәлил хәзрәт тапшырды.

Командалар арасында Чаллы шәһәре командасы җиңде һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте кубогына лаек булды.

# Беренче адымнар

Чаллының "Ихлас" мәчетендә "Ислам. Беренче адымнар" дигән үзенчәлекле укулар оештырыла. Әлеге интенсив мәктәп ислам динен өйрәнүгә тәүге адымын атлаучыларга ярдәм итүне күздә тота.

Интенсив программа кыска вакыт аралыгында шактый күп мәгълүмат алырга мөмкинлек бирә, мәчеттә уздырылу нәтиҗәсендә, әлеге белемне практик яктан ныгыту өчен дә уңайлы була. Мондый курслар дин тәртипләрен белмәгән, мәчет каршындагы мәдрәсәләрдә укырга вакыт җиткерә алмаган, әмма дини канунннарны өйрәнергә теләгәннәр өчен бик файдалы булыр дип көтелә. Тәһарәт алу тәртибеннән башлап, намаз укырга өйрәнү, ислам нигезләре белән танышу өчен 5 дәрес каралган, атнага бер дәрес үткәрелә.

Дәресләр Сидоровка бистәсендә урнашкан "Ихлас" мәчетендә шимбә көннәрендә иртәнге 9 дан сәгать бергә тиклем узачак. Тәүге дәрес 14 апрельдә була. Теләге булганнар бу курсларга 89179316571 телефоны аша языла ала.

# Кукмарада ачык дәрес

Кукмара мәдрәсәсендә методик көннәр кысаларында ачык дәрес узды. "Фикх" дәресен Кукмара мәдрәсәсенең уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Рифат хәзрәт Ибраһимов алып барды. "Хаҗ фарызлары" темасы гади, аңлаешлы телдә, күптөрле күрсәтмә материаллар кулланып үтте. Ачык дәрескә килгән Диния нәзарәте, Россия ислам институты, Мамадыш мәдрәсәсе вәкилләре дәреснең югары дәрәҗәдә алып барылуын билгеләп уздылар. Мәдрәсә җитәкчесе Ришат хәзрәт Курамшин ачык дәреснең уңышлы үтүендә Илгиз хәзрәт Шәймиевнең дә өлеше барлыгын ассызыклады. Теманы аңлатканда дәрес-сәяхәт формасын куллану, укытучы - хаҗга баручы төркем җитәкчесе, ә студентларның хаҗилар ролендә булуы дәреснең кызыклы һәм файдалы үтүенә бер нигез иде. Барлык чыгыш ясаучылар: "Мәдрәсәнең әлеге махсус җиһазландырылган кабинетын хаҗга барырга әзерләнүче Кукмара мөселманнарына консультация максатында кулланырга мөмкин", - дигән уртак фикергә килделәр.

***

"Ихлас" мәчете вәкилләре Чаллының 2 нче гимназиясендә укучылар белән очрашу уздырды. Очрашу барышында хәзрәтләр балаларга этиәниләр һәм, гомумән, башка кешеләр белән мөнәсәбәт нинди булырга тиешлеге хакында сөйләде.



# КӨНЧЕЛЕК ГОМЕРНЕ КЫСКАРТА

Гөнаһларның да, бозыклыкларның да төрлесе бар. Бозыклыкларның иң олысы - аракы эчү. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм: "Аракы эчү - бозыклыкларның анасы", - дигән. Бөтен бозыклыкның башы шуннан башлана. Гөнаһларның иң олысы бар - ул Аллаһ Тәгаләгә ширек кылу. Бу - Аллаһ Тәгаләдән башка табына торган тагын бер зат бар дип әйтү, йә булмаса, Аллаһ Тәгаләнең барлыгын шик астына алу, йә булмаса, Аллаһ Тәгаләдән башка берәүнең ниндидер эшкә көче җитә, дип уйлау. Гөнаһларның әүвәле бар, гөнаһларның беренчесе бар. Гөнаһларның әүвәле, гөнаһларның беренчесе - башы көнчелектән башлана. Менә шушы көнчелек адәм балаларының башка гөнаһларының башы булып тора. Гайбәт сөйләү, телне тыймау, начар сүзләр әйтү, утынны ут ашаган шикелле, изге гамәлләрне ашап бетерергә мөмкин. Урынсызга бәндәне рәнҗетсәк, урынсызга кешене үпкәләтсәк, аның гамәл дәфтәренә безнең бер яхшылыгыбыз күчә, йә булмаса, теге адәмнең бер яманлыгы безнең гамәл дәфтәренә күчә. Көнчелек тә - нәкъ шушындый яман гадәт. Ул да утынны ут ашаган шикелле, безнең изге гамәлләребезне юкка чыгара. Көнчелек безнең изге гамәлләребезне генә түгел, безнең үзебезне дә юкка чыгара ала. Безнең сәламәтлегебезне ашап бетерә. Китапларда әйтелгән: адәм баласының гомерен бурычка алу, үлгән кешенең йөзен карау, сәдака алу, авыру һәм көнчелек кыскартыр, диелгән.

Көнчелек тә безнең сәламәтлегебезне бетерә, ул - бик яман чир.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: «Минем өммәтемдә дә өч төрле кимчелек бар. Алар әле һаман йолдыз гыйлемнәре белән шөгыльләнәләр, алар төрле шомлануларга, ырымнарга да ышаналар, аларның күңелләрендә көнчелек тә бар», - диде. Адәм булган кешедә, нәфес булган кешедә көнчелек, әлбәттә, булмый калмый инде. Әмма иманлы кеше үзенең иманы, гыйлеме белән шушы көнчелекне тыеп торырга тиеш. Ул аның киңәеп, әрсезләнеп, авыруга әйләнүенә юл куймаска, тышка да чыгармаска тиеш. Авыруның кечкенә генә билгеләре сизелә башласа, без табибка барабыз, дарулар эчәбез, авыртуны басарга тырышабыз. Көнчелек тә - шундый чир. Бездә нәрсәгәдер шундый борчылу, көнчелек бар икән, тизрәк тәһарәт алырга, намазлар укырга кирәк, алай итеп тә баса алмасаң, ураза тот. Һәм Аллаһ Тәгаләдән күңелендәге шушы чирне чыгаруын сорарга кирәк. Чөнки, әйткәнемчә, утынны ут ашаган шикелле, көнчелек безнең гамәлләребезне генә түгел, Аллаһ Тәгалә безгә әманәт итеп биргән сәламәтлегебезне дә бетерүгә сәбәп булып тора. Дөнья яралтылганнан соң, җаннар яралтылганнан соң, Аллаһ Тәгалә адәм баласын балчыктан яралтты, фәрештәләрне нурдан, җеннәрне уттан яралтты. Һәм шушы балчыктан яралтылган адәмне Аллаһ Тәгалә бөтен нәрсәдән өстен куйды.

"Ләкаде халәкънәл-иңсәәнә фии әхсәни тәкъуииим". "Без кешене иң яхшы сурәттә барлыкка китердек", - диелә «Әт-Тин» («Инҗир агачы») сүрәсендә (95:4). Икенче төрле әйтсәк, мин кешене, адәм баласын бөтен нәрсәдән өстен итеп яралттым, ди Аллаһ Раббыбыз.

«Үә сәххара ләкүм мәә фииссәмәәүәәти үә мәә фил әрдый җәмиигәм-минһү, иннә фии зәәликә ләә әйәәтил-ликаүмиййәтәфәккәрүүүн». - Һәм бөтен нәрсәне адәм баласы өчен, адәм баласы файдалансын өчен яралттым, ди. Һәм үзе яралткан бар мәхлукатка, бөтен җан ияләренә адәмгә сәҗдә кылырга кушты. Шушы вакытта бер Иблис кенә сәҗдә кылмады. Адәм баласыннан көнләште ул. Мин уттан яралтылган килеш, ничек итеп балчыктан яралтылган адәм баласына сәҗдә кылыйм, диде. Һәм шушының өчен ул Аллаһ Тәгаләнең ләгънәтенә тарды. Иблис ләгыйнь булып калды. Көнчелек Иблисне шушы хәлгә төшерде. Ул исә фәрештәләрдән дә галим, укымышлы иде. Газазил исемле фәрештәләрнең укытучысы иде ул. Һәм менә ул көнчелек аркасында Иблис ләгыйньгә әйләнде. Үзен Аллаһ Тәгаләдән өстен куйды. Бу - дөньяда эшләнгән беренче гөнаһ булды. Һәм бу гөнаһ - көнчелек нәтиҗәсендә.

Икенче гөнаһ җирдә эшләнелде. Ул да көнчелек нәтиҗәсендә булды. Кабил белән Һабил - икесе, Аллаһ ризалыгы өчен, дип, корбан чалдылар да, Һабилнең корбанын Аллаһ Тәгалә кабул итте, Кабилнекен кабул итмәде. Кабилнең корбаны начар сыйфатлы иде. Һабил әйтте Кабилгә: күңелендә бозыклык булган, йә булмаса, үзендә хәрам булган кешенең догасын, корбанын Аллаһ Тәгалә кабул итми, диде.

Кабил бу хакта: минем күңелемдә бозыклык бардыр, мин хәрамга да катышамдыр, шуныннан тыелырга кирәк, пакьләнергә кирәк, дип уйланырга тиеш иде. Әмма ул, Һабилнең кабул ителгән корбаныннан көнләшеп, Һабилне үтерде. Көнләште. Җир йөзендә булган беренче гөнаһ та менә шулай көнчелек нәтиҗәсендә булды. Без, адәм балалары, иманлы кешеләр, үзебез-не-үзебез шушы көнчелек, хәсетлек дигән чир белән бимазаламаска тиеш, без аны тыеп торырга тиеш. Басуны чүп үләне басса, аны утап торалар. Адәм баласы да үзен көнчелектән арындырырга тиеш. Без шундый зәгыйфь булганыбызга күрә, төрле көнчелекләргә, хәсетлекләргә бик тиз бирешкәнебезне күреп, Аллаһ Тәгалә биш тапкыр тәһарәт алып, намаз укуны фарыз кылды.

Кеше биш тапкыр намазын укымаса, күңелен кирәкмәгән уйларга юнәлтеп, көнчелеккә бирелеп, үзен-үзе бетерергә мөмкин. Әмма аның намазы да риядан түгел, ихластан, чын күңелдән булырга тиеш. Шул чакта гына ул көнчелектән шифа булыр.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең бер хәдисе бар: «Мөселман кеше үзенә теләгәнне башкаларга теләми торып, ул мөселман булмас». Шуңа күрә болай дога кылабыз. Нәрсә дип? - "Раббәнәгъфир лии үәли үәәли дәййә үә лилмүэми-ниинә йәүмә йәкуумүл-хисәәәбе. - Раббыбыз! Мине һәм минем ата-анамны һәм иман китергән кешеләрне хисап булачак көндә ярлыка!" (14 нче «Ибраһим» сүрәсе, 41 нче аять). «Йа Раббым, үземне ярлыка, йа Раббым, әти-әниемне ярлыка, йа Раббым, остазларымны ярлыка, йа Раббым, бөтен мөселманнарны ярлыка», - дип. Үзебезгә сораганны башкаларга да сорыйбыз. Безнең иманның бит яртысы - сабырлык, яртысы -шөкеранә. Иманнарыбызның зәгыйфь булуы канәгатьсезлеккә китерә, бездә хәсетлекне уята. Без кешедән күпсенәбез, үзебезнекен әзсенәбез. Аллаһ Тәгалә әйтте: кем гамәлне әзрәк кылса, шайтан аның күңеленә вәсвәсә салыр, байлыгы таулар хәтле булса да, аның күңеленә аз булып күренер. Ризыгы таулар хәтле булса да, бетәр күк тоелыр һәм ул канәгатьләнү тапмас. Күңелнең чире - хәсетлектер, көнчелектер, - диде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм дә: ялкау кешенең дусты булмас, ялганчы кешегә ышанучы булмас, көнчә кешенең күңеле тыныч булмас, дигән.

Аллаһ Тәгалә бер кешегә дәүләт бирә икән, без аннан көнләшәбез икән, димәк, без Аллаһ Тәгаләнең бу кешегә бирүеннән көнләшәбез булып чыга. Бер сәхабәдән сораганнар: син кешеләрдән көнләшәсеңме? - дип. "Нишләп мин кешеләрдән көнләшим? Берәүнең байлыгы күп, ул рәхәт яши, дип көнләшер идем, бәлки аның тәкъдире җәһәннәмдер. Әллә бу байлык аны җәһәннәмгә алып баручы, тәмугка алып керүче байлыктыр. Шушы кешегә тәкъдирләнгән тәмуг өчен мин аннан көнләшимме? Йә булмаса, берәүнең гамәлләре аны җәннәткә алып бара торган булса, Аллаһ Тәгаләнең бу кешегә биргән нигъмәтеннән күпсенимме?" - дигән.

Берәүдән күпсенсәң, Аллаһ Тәгалә үзеңнекен юк итәр. Бу кешегә гамәлләр өчен җәннәт насыйп булган икән, без аны күпсенәбез икән, димәк, безнең үзебезгә насыйп булырдай җәннәтне югалтуыбыз бар, Аллаһ сакласын.

Бу - сынау дөньясы. Аллаһ Тәгалә дәрәҗәне дә, байлыкны да безгә сынау өчен бирә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең мондый хәдисе бар: дөньяда сез - һәркайсыгыз көтүчедер, һәркем үзенең көтүе өчен җавап бирер, ди. Кеше нихәтле зуррак дәрәҗәгә ирешкән саен, нихәтле зуррак дәрәҗәле урынны биләгән саен, Аллаһ Тәгалә каршында җавап бирәсе дә күбәя бара. Ул тәмугка да тизрәк керергә мөмкин. Бу - бик куркыныч сынау. Берәүгә шундый сынау куелган икән, берәүне Аллаһ Тәгалә шулай сыный икән, йә булмаса, Аллаһ Тәгалә берәүне байлык белән сыный икән, моңардан иманлы адәм һич көнләшмәскә тиеш.

Һәм инде дога кылып, йа Раббым, нинди яхшылыклары өчен шушы бәндәңә нигъмәтләр бирдең, йа Раббым, миңа да изге гамәлләр кылып, шушындый дәрәҗәләргә, нигъмәтләргә ирешергә насыйп кыл, дип Аллаһ Тәгаләдән сорарга кирәк. Менә шулай итеп сораса, бу көнләшү булмый. Изге гамәлләр кылуда кешенең көнләшүе дөрес булып санала. Әйтик, берәү күп-күп итеп намазлар укыса, иртә-кич Коръән укыса, зекердә утырса, икенче кеше, мин нишләп бу кешедән калышам әле, бу адәм җомга намазына йөри бит, мин дә аңардан калышмыйча, җомгага йөрим әле, ул биш вакыт намаз укый бит, мин дә укыйм әле, бу кеше ураза тота бит, мин дә аңардан киммени, мин дә ураза тотыйм әле, дип көнләшсә - дөрес көнләшү. Мондый көнләшү һич гөнаһ түгел, һәм инде бер кеше малыннан сәдака бирсә, ул кеше бирә, нишләп мин бирмим әле, дип, гошерләрен, зәкятләрен бирсә, бу көнләшү дә - дөрес көнләшү булып тора. Хәсетлек булмый бу. Моның өчен гөнаһ юк. Без күңелебездән көнләшеп, бер кешегә начарлык теләп йөрсәк, йә булмаса, аның байлыгы бетүен теләсәк, йә булмаса, аның сәламәтлегеннән көнләшсәк, бу Аллаһ Тәгаләгә билгеле була. Яманлыкны язып баручы фәрештә безнең кылган начар гамәлләребезне генә түгел, ә уйлаган яман фикерләребезне дә дәфтәренә теркәп бара. Шул гамәлләребез өчен җавап бирергә туры киләчәк.

Шуңа Коръәндә Аллаһ Тәгалә әйтә: «Үә иң түбедүү мәә фиии әнфүсикүм әү түхфүүһү йүхәәсибекүм биһи лләәәһ». Әгәр сез күңелегездәге ачыкласагыз яки яшерсәгез, моның өчен Аллаһ сездән хисап алыр. («Әл-Бәкара» сүрәсе, 284 нче аять). Күңелегездәге начар уйларыгыз өчен, әлбәттә, җавап тотасы булыр.

Шушы аять иңгәч, сәхабәләр, күңелгә ниләр генә килми,барысы өчен дә җавап бирәсебез бар икән, дип, бик курыкканнар. Шуннан соң Аллаһ Тәгаләдән тагын бер аять иңгән. «Ләә йүкәллифү-ллааһү нәфсән илләә үүсгаһә, ләһәә мәә кәсәбәт үә гәләйһәә мәкгәсәбәт». - Мөмкин булмаган башка һичбер нәрсәне Аллаһ җанга йөкләми. Нәрсә казанган булса - аңа һәм аңа каршы да - үзе казанганы. (2:286). Кеше күңеленә килгән бозыклыкны тыеп торса, аны тышка чыгармаса, начар уе өчен тәүбәгә килсә, әлбәттә, аның өчен җавап тотмас, ди Аллаһ Тәгалә.

Безнең күңелебезгә бер начар ният килергә мөмкин, әмма аны тормышка ашырырга җай чыкмый, мөмкинлек булмый. Менә бу очракта инде без шул эшне эшләгән шикелле үк гөнаһлы булабыз.

Без аны кылмадык та, күңелебездә генә калды, әмма Аллаһ Тәгалә алдында гөнаһка баттык, чөнки бу бит иманның зәгыйфьлеге билгесе. Тәүбәгә килим әле, мин бу эшне эшләмим әле, дип кире уйласак, әлбәттә, бу уебыз өчен безгә гөнаһ булмый.

Шуңа күрә Аллаһ Тәгалә барчабызның да күңелләренә сабырлыклар биреп, Аллаһ Тәгалә кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә насыйп итсә иде. Телебезне тыя алмау, гайбәт, көнчелек шикелле, иманлы кешеләргә хас булмаган, иманлы кешеләрнең иманын зәгыйфьләндерә торган гамәлләрне гамәлләрне эшләмәскә Аллаһ Тәгалә безгә сабырлыклар бирсә иде. Барчабыз да хәрамнардан тыелып, Аллаһ Тәгалә кушканнары үтәп яшәсәк иде.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,**
**Татарстанның баш казые.**

## Колак салсаң, үкенмәссең

* Көнче кешенең явызлыгыннан Таңның Раббысы Аллаһка сыенамын

* Мөэминнең йөрәгендә иман белән көнчелек бергә була алмаслар

* Көнчелектән саклана күрегез. Дөреслектә ут утынны ашаган кебек, көнчелек тә эшләгән изгелекләрне, савапларны ут кебек ашыйдыр

* Кешеләр гел хәерлектә булырлар, әгәр дә бер-берсенә көнчелек кылмасалар

* Бел, көнчелек — ул йөрәк чирләренең иң авыры. Бу йөрәк чире фәкать гыйлем белән генә дәвалана. Гыйлем — ул көнчелекнең зарары фәкать сиңа гына кайта икәнен аңлавың. Көнчеләнгән кешеңә синең көнчелегеңнән бер зарар да килми. Үзеңнең дошманың булма, шайтанның ярдәмчесе дә булма

## БЕЛӘСЕЗМЕ?

Бәраәт кичәсе - шәгъбан аеның 14еннән 15 нче көнгә каршы кичендә була. Бәраәт сүзе гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә, “берәр авырлыктан - бурыч вә җәзадан котылу” мәгънәсен белдерә. Кем дә кем бу кичтә тәүбә-истигъфарлар кылып, кылган гөнаһлары өчен гафу үтенсә, шул узган елда кылынган гөнаһлары кешенең гамәл дәфтәреннән сызылыр. Соңыннан алдагы бер ел өчен бөтен мәхлукатның, бөтен барлыкларның ризыклары, байлык вә ярлылык хәлләре, дөньяга мөнәсәбәтле дәрәҗәләре, шул киләчәк ел эчендә туачак һәм вафат булачак кешеләр - барысы да бу кичне билгеләнер. Бу кичә бик фазыйләтле һәм нурлы кичә булып санала. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткәнчә, Бәраәт кичәсе - догалар вә теләкләр кабул була торган бер кич. Бу кичтә намаз уку, дога кылу, әрвахлар өчен Коръән уку киңәш ителә. Бәраәт көнен ураза тотып уздыру - Пәйгамбәребезнең сөннәтедер.

### ӘДӘБИ СҮЗ

## Кичер, Раббым

*Кичер, Раббым, гөнаһларым булса,*
*Хаталарым булса, гафу ит.*
*Белеп-белми кылган ялгышларга*
*Этәрүче язмыш үзе бит...*
*Кичерә күр, кайчак абынуым*
*Начар ният белән түгел лә.*
*Бөртек кадәр хәтта явызлык юк,*
*Гел яхшылык кына күңелдә...*
*Ялгышлар да булмый калмагандыр,*
*Гафу сорыйм, кичер, Раббым, дип.*
*Ярый син бар, кыен чакларымда*
*Тынычлыкны синдә таптым бит...*

***

*Әниемнең өзгәләнеп әйткән*
*Сүзен бик еш искә алам мин:*
*“Бәхет, тәүфыйк, саулык белән бергә*
*Балаң өчен гомер сора син...”*
*Әллә инде сорый белмәдемме?..*
*Яшь пәрдәсе каплый күзләрен...*
*Дога итеп күңелемдә йөртәм*
*Әниемнең шушы сүзләрен...*
*Шуңадырмы, һәр иртәне башлыйм,*
*Иминлекләр сорап тын гына.*
*Гомерләр бир газиз балаларга,*
*Һәр эшләре булсын уң гына!*
*Бала бит ул - бавыр ите, диләр,*
*Ә минемчә, бала - йөрәгең!*
*Бала хәсрәтләре бирмә, Раббым,*
*Көн тудымы – шушы теләгем!*

**Гөлара ШӘРИПОВА,**
**Арча.**

## Зәмзәм суы

Бүгенге сүзебез Җир йөзендәге иң мөбарәк су - Зәмзәм турында. Зәмзәм чишмәсенең тарихы моннан меңнәрчә еллар элек яшәгән Пәйгамбәребез Ибраһим галәйһиссәләм исеме белән бәйле. Аллаһ кушуы буенча, Ибраһим галәйһиссәләм хатыны Һаҗәр анабызны һәм кечкенә улы Исмәгыйльне чүл уртасында калдырып китә. Ләкин ерякта да аларның исәнлеге-иминлеге өчен күп догалар кылып тора. Һаҗәр анабызның суы беткән була. Һәм ул, су эзләп, Сафа белән Мәрва таулары арасын кат-кат йөгереп үтә. Әмма су тапмый. Аллаһтан ярдәм сорап, догалар кылып барганда, кинәт улы калган тарафта су тавышын ишетә. Аллаһның киң рәхмәте белән, кечкенә Исмәгыйльнең үкчәсе турыннан көчле агым булып Зәмзәм чишмәсе бәреп чыккан! Тора-бара чүл уртасында су булганын белеп, Һаҗәр янына кешеләр җыела башлый, шулай итеп бу изге урында Мәккә шәһәре төзелә.

Ибраһим галәйһиссәләмгә якын кешеләрен чүлдә калдырып китү, әлбәттә, бик авыр була. Ләкин ул Аллаһ кушканны берсүзсез үти, чөнки бу илаһи сынауда зур хикмәт барын аңлый. Һаҗәр анабыз да тәкъва, ихлас хатын була, Аллаһ әмеренә буйсына. Күз алдыгызга китерегез: сусыз, ризыксыз, бер җан әсәре булмаган эссе чүл уртасында күкрәк баласы белән берьялгызың калуның авырлыгын. Никадәр сабырлык, Аллаһның чиксез мәрхәмәтенә никадәр көчле ышаныч булу кирәк йөрәк түрендә! Бу безнең өчен, әлбәттә, искиткеч тәвәккәллек, үзеңне тулаем Аллаһка тапшыру үрнәге!

Зәмзәм – тукта, таралып китмә дигәнне аңлата. Һаҗәр анабыз Зәмзәмнең бик мул булып, гөрләп акканын күргәч, “Зәм, зәм”, - ди. Ягъни татарчага тәрҗемә итсәк, бу бәрәкәтле чишмә туктасын, таралып китмәсен, дип әйтә. Һаҗәр анабызның бу ихлас догасын Аллаһ кабул иткән. Һәм моны бүгенге галимнәр зәмзәм коесындагы су күләмен тикшереп, хәтта дәлилләгәннәр дә. Бу чишмә меңнәрчә еллар дәвамында саекмыйча, мул тора. Хәзерге заманда Зәмзәм коесында махсус электронасослар эшли һәм зур су заводы урнашкан. Һәркөнне миллионлаган хаҗилар һәм дөнья буенча миллионлаган мөселманнар шушы мөбарәк су белән тәэмин ителә. Галимнәр махсус исәпләп чыгарган: әгәр тәүлек буена Зәмзәм коесыннан 690 миллионнан артык литр су алынса, ул янәдән шул ук күләмне нибары 11 минут эчендә кайтара икән. Тәүлек буена югалткан миллионлаган литр суны ниндидер 11 минут эчендә генә кабат тутыру - бу бит үзе үк шундый зур могҗиза, мә шә Аллаһ! Аллаһы Тәгалә Зәмзәмне бик көчле, куәтле агымлы һәм бәрәкәтле иткән. Ләкин монда акылга сыймаслык икенче нәрсә дә бар: ничек Зәмзәм коесы шундый зур тизлек белән тула, ләкин артыгы агып та чыкмый?! Аллаһ Зәмзәмнең чиген билгеләгән – бу икенче зур могҗиза! Әйтерсең лә, Зәмзәм чишмәсендә суны кыса торган күзгә күренмәс серле боргыч бар! 11 минут саен бертуктаусыз миллионлаган литр су агып чыга башласа, бар дөнья тора-бара Зәмзәм суына батар иде. Нәкъ Һаҗәр анабыз сораганча, Аллаһ Зәмзәмне бәрәкәтле дә иткән, шул ук вакытта Үзенең чиксез Кодрәте белән аңа чик тә куйган!

Аллаһ бар иткән дөньябызга күңел күзе белән карап, фикерләп яшик, дусларым. Әссәләмүгаләйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәракәтүһү!

**Язманы “Хәзинә” клубы мөгаллимәсе Әлфия МӨДӘРИСОВА әзерләде.**

## *Яхшылыкта ярышыйк*

– Әтисе, – диде Җәмилә иренә. – Әтисе, – дим. – Торырга кирәк. Эшкә соңга каласың. Хәзер чәй куеп җибәрәм, юын, – дип, чыгып китте аш бүлмәсенә Җәмилә.

Будильникның кирәге юк Мөниргә. Иртәнге дүрттән чыгып китәсе булса да, хатыны аны һәрвакыт уятып, җылы ашын ашатып, эшкә хәстәрләп җибәрә. Иртә таңнан көне буе автобус клиндере әйләндерерлек хәле дә, дәрманы да бар Мөнирнең.

Бүген дә шундый иртәләрнең берсе. Таң беленә. Йортлар арасыннан сызылып кына яктылык сизелә. Шәһәр әле һаман йокыда. Анда-санда юлдан машиналар уза. Автобусларга да кузгалырга вакыт. Кешеләрнең эше башлана.

Чәй табыны янына килеп утырганда, өстәлгә иртәнге чәй ясап куелган, аның янына күкәй тәбәсе, ипи. Төшкә дигән аш та төенләнеп, сумкага салынган. Көн дә шул ук хәл. Иртән торыла, ашап-эчелә дә тагын эшкә. Хатын өйдә: балаларны мәктәпкә озата, алардан соң юа, җыя. Тагын аларны каршы ала, кич дәрес әзерләшә, тагын өстәлгә ашарга куярга. Өй мәшәкатьләрен Мөнир белми, аларга катышмый. Җәмилә сораса, ватылган, җимерелгән вак-төякне ямаштыра. Акчасын алып кайтып бирә дә тагын эшкә чыгып китә.

Тормыш шулай әкрен генә бара. Җәмилә зарлана торган хатыннардан түгел. Булганына шөкер итә, җитмәгәненә сабыр итә белә. Зарплата дигәннәрен ай ахырына ялгый хатын.

Чәй алдында өстәлгә куелган ризыкларга карап, Мөнир:

– Җиткерә аласыңмы, анисе? – дип сорап куя. Җәмилә аңлый аның җиткерә аласыңмы дигәнен.

– Әйе, әтисе, булганына шөкер. Фатирга вакытында түләп барам: утка, суга җитә. Малайлар мәктәптә ике мәртәбә ашый. Өсләренә бар, киемнәрен ертмыйлар.

Тәртипле йөриләр. Айрат улыбыз конструктор түгәрә-генә йөри. Түләүле түгәрәк булса да йөртәм әле. Иткә акча кирәкми, әни исән булганда авылдан килә. Ипи, сөткә җитә, аз-маз гына өйне дә киендерәм. Үземә дә шунда иннек-кершәнгә арта. Җитә, әтисе, җитә, – дип тезеп китәсе иде дә, тыела, шунда тукталып:

– Ләкин бер нәрсәгә генә күңел китек: автобусың иске. Күреп торам, гел шуны җайлыйсың, майлыйсың. Көне буена, берәр җире җимерелеп төшмәсә ярар иде дип, борчылып та йөрисең инде. Ватык автобус белән кеше ташу җиңел түгел инде, беләм, – дип көрсенеп куйды да дәвам итеп, – хатын-кыз кайгырта торган нәрсә түгел дә, уйлата бит, – диде Җәмилә.

Мөнир дәшмәде. Һәр көн диярлек шул автобус мәшәкате. Элек атлы кеше ашлы булган, хәзер машиналысы. Арык ат белән эш җимерә алмаган кебек, җимерек автобус белән әллә ни кырып булмый шул дигән уйлары Җәмиләнеке белән ялганды.

Җәмилә, артыгын әйтеп ташладым ахрысы дип, Мөнирнең күзләренә карады. Мөнир:

– Нишләтәсең инде, әнисе, эшләргә кирәк бит, ватык булса да, җайлагач, майлагач йөри. Яңасын бирмиләр бит, – диде.

Җәмилә, ире эшкә чыгып китәр алдыннан кәефен төшермим инде, дип:

– Исән-сау гына йөре, – дигән йомшак сүзләре белән Мөнирне ишектән озатып калды.

Бу сөйләшү Мөнир күңеленә тәэсир итмәде түгел, нык тәэсир итте. Уйларыннан арынырга теләп, тиз-тиз эшенә атлады. “Булганына шөкер итәргә, көнлек эшеңне җиренә җиткереп башкарырга кирәк. Әнә күпме кеше син йөртә торган автобуска утырып эшенә бара. Җитештерергә кирәк ул кешеләрне. Бу дөньяда һәр кешенең үз вазыйфасы бар. Яхшылыкта ярышырга кирәк. Булганы белән дә эшли белергә кирәк”, – дип көндәлек урынына – автобус утыргычына менеп утырды. Үзенең уйларыннан җиңел булып китте. Йөзендә елмаю артты. Автобусның алгы тәрәзәләрен юеш чүпрәк белән, аннан коры чүпрәк белән сөртеп алды. Дөньяга карый торган тәрәзәләребез чиста булсын. “Бисмиллаһиррахмәнирраһим, киттек, автобус дустым, кешеләрне эшләренә илтеп куйыйк!” – дип автобусын кабызды. Көне буе шәһәрнең бер башыннан икенче башына кеше ташу Мөниргә чыннап ошый. Кешеләр ашыгалар, кабаланалар, тәрткәләшәләр, әйткәләшәләр. Кызык, автобустан да алда барып җитәргә тырышалар. Автобустагы кешеләр дөньясы - үзе бер дөнья. Нинди генә кыяфәттә, нинди генә холыкта яратмаган Аллаһ аларны. Гаҗәп, көне буена кешеләр турында фильм караган кебек күзәтә Мөнир аларны. Автобус алып бара торган юл да – тормышның кечкенә бер сукмагы кебек. Ул сукмакта нәрсә генә очрамый да нинди генә хәлләр булмый. Шундый уйларыннан эш сәгате беткәнен дә сизмәгән Мөнир. Кич якынлашып килә. Шәһәр утларын кабыза. Хәрәкәтләнүчеләр сирәгәя. Арылган. Соңгы тукталышта соңгы кешене калдыргач, өйгә кайтырга кирәк, дип, ишекләрне япты Мөнир. Инде кайтырга кузгалам дигәндә генә, өстенә күн куртка кигән, кулына күн сумка тоткан ниндидер ирнең автобусны туктатырга теләп кул болгаганын шәйләде. Кулындагы сәгатен күрсәтеп, вакыт чыкты дип, ымласа да, ирнең үҗәтләнгәнен күреп, автобусын туктатты. Ишеген ачты. Ир, ашыга-кабалана:

– Брат, мине Үзәк урамга хәтле ал әле, бик ашыгам, – диде.

Мөнир эш сәгате беткәнен, эш сәгате беткәч, кеше алырга ярамаганлыгын аңлатырга теләп караса да, ирнең: «Бик ашыгам, брат, бик ашыгам, чынлап ашыгам», – дигәненә, «Утыр», – дип кенә җавап кайтарды да, автобусны кире шәһәр эченә алып кереп китте.

Тукталышка китереп җиткергәч, автобусны туктатты да ишекне ачып:

– Килеп җиттек, Үзәк урам тукталышы, – дип ишеккә ымлады. Ир:

– Мә, брат, шуннан да ваграгы юк, – дип кесәсеннән бер меңлек чыгарды.

– Юк, акчаң кирәкми, мин бит чын күңелемнән, – диде дә Мөнир ишекләрне япты.

Күңел өчен күп кирәкми! Кечкенә генә яхшылык та эшләү җитә. Яратып хезмәт итү, эшеңнән тәм табу, кешеләргә кирәкле булуыңны аңлаудан рәхәтрәк хис бар микән?!.

**Гөлфия Насыйбуллина.**

